Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

№ 9 (9)

1 декабрь 2011 ел

## ● Атнаның җиде вакыйгасы

24 ноябрь көнне Мәскәүдә Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университеты һәм Казан (Идел буе) федераль университеты арасындагы хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куелды. Федераль дәрәҗәдәге Казан университеты өчен әлеге килешүнең әһәмияте аеруча зур. Медицина һәм фармакология, җитештерү өлкәсе, икътисад, интеллектуаль хезмәт базарына бәйле уртак фәнни проектларны тормышка ашырыр өчен яңа мөмкинлекләр ачыла. Үз чиратында, Мәскәү галимнәрен КФУның Геология һәм кара алтын-газ институты, Кара алтын һәм табигый битумнар үзәге эшчәнлеге кызыксындырмый калмас.

• • • •

Шул ук көнне университетка Япониянең Милли астрономия обсерваториясе вәкилләре килде. Делегация составында профессорлар Нурики Кавагучи һәм Хидэу Ханада бар иде. Япония кунаклары КФУның тышкы элемтәләр буенча проректоры Линар Латыйпов, Физика институты директоры Альберт Аганов һәм институт профессорлары белән очрашты. Алар астрономия, айның әйләнеше һәм эчке төзелеше, планета спутникларына бәйле проблемалар турында фикер алыштылар. РФнең һәм Япониянең халыкара космик проектларда катнашуына, фәнни-техник кадрлар әзерләү, студентлар, аспирантлар, галимнәр белән алмашуга бәйле сораулар да каралды.

• • • •

25-27 ноябрь көннәрендә КФУда студент һәм аспирантларның «Модернизацияләү шартларында дәүләтчелекне хокукый рәвештә тәртипкә салу: милли һәм халыкара аспект» VI Халыкара фәнни-гамәли конференциясе узды. Инде алтынчы ел рәттән Россиянең генә түгел, ә ерак һәм якын көнчыгыш төбәкләрдән студент һәм аспирантлар юриспруденция өлкәсендә булган фәнни эшләнмәләре белән уртаклашырга җыелалар. 500дән артык гариза кабул ителгән конференция 12 секциягә бүленеп эшләде. Шулай ук КФУның танылган галимнәре лекцияләр укыды, мастер-класслар уздырды.

• • • •

Бу атнада «Казан ярминкәсе» күргәзмәләр үзәгендә III махсуслаштырылган «Нанотехнологияләр. Казан – 2011» күргәзмәсе үтте. Биредә нанотехнологияләр файдаланып продукция җитештерә торган предприятиеләр һәм аерым югары уку йортлары катнашты. Наноиндустрия өлкәсендәге уңышлары белән Казан университеты да бүлеште. ТР Президенты Рөстәм Миннеханов бүгенге көндә мондый оешмаларның күбрәк булырга тиешлеген искәртте.

• • • •

Кичә, ягъни 30 ноябрь көнне Филология һәм сәнгать институтының сәнгать бүлегендә 2011-2012 уку елы музыкаль-белем бирү лекториесенең III концерты булды. «Viva Opera» дип аталган әлеге кичәдә тамашачылар сәнгать бүлеге мөгаллимнәре һәм кунаклар – М.Җәлил исемендәге Опера һәм балет театры, ТР Дәүләт филармониясе солистлары, Н.Җиһанов исемендәге консерватория студентлары һәм укытучылары башкаруында төрле опералардан өзекләр тыңлады.

• • • •

Бүген Казан университетында зур чара – Н.И.Лобачевскийны искә алу кичәсе уза. Университет тарихы музеенда Лобачевский залы эшли. «Даһи галим, ректор, Бөек Россия Гражданины» дигән экскурсия һәркем күңеленә хуш килә. «Лобачевский», «Загадка Лобачевского» фильмнарында галим турында бик күп мәгълүмат тупланган. Н.И.Лобачевский һәйкәленә чәчәкләр кую да чараның иң матур мизгелләре булып истә калыр.

• • • •

Иртәгә, ягъни 2 декабрь көнне «Ел студенты – 2011» Татарстан Республикасы студентлар премиясен тапшыру тантанасы була. «Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексында узачак чарада ТР Президенты Рөстәм Миннеханов та катнашачак. Конкурсантлар 16 номинация буенча бүләкләнә. Чарадан тулырак мәгълүматны алдагы саннарда укый алырсыз.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



prav.tatar.ru

# Җиңүче - КФУдан!

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

16 майдан 30 ноябрьгә кадәр ике этапта узган Яшьләр форумына 16-30 яшьлек югары һәм урта уку йортлары студентларыннан, балалар һәм яшьләр оешмалары активистларыннан 849 гариза кабул ителгән. Финалга узган 75 проектның 35е күргәзмәдә урын алды.

Икенче тапкыр уздырыла торган республика Яшьләр форумы һәр яшь кеше яисә команда өчен үз талантыңны күрсәтү мөмкинлеге бирә. Аның максаты да икътисади, социаль, инновацион яктан, авыл хуҗалыгына бәйле файдалы идеяләрне тормышка ашыру өчен актив яшьләргә мәйдан булдырудан гыйбарәт. Уйлап тапкан проектың дәүләт кешеләре алдында кызыксыну уятса, алга таба сине зур уңышлар көтә дигән сүз. Форумда катнашучылар саны елдан-ел арта. Димәк, яшьләр җәмгыять эшләре белән кызыксына һәм аның киләчәген төзүгә үз өлешен кертергә тели.

Форумга эшләр төрле тематикаларга бүлеп кабул ителә. Безнең университетка да җиңү килде. Филология һәм сәнгать институтының татар филологиясе бүлеге хезмәткәре Ландыш Хәмит кызы Фазуллина «Киләчәккә старт!» номинациясендә, «Тылсымлы куллар» балалар журналын тәкъдим итеп, беренче урынны алды. Балалар журналы мавыктыргыч, кызыклы, эчтәлекле булуы белән игътибарны җәлеп итә.

«Журналыбыз 5-8 яшьлек балаларны иҗади һәм танып белү, рухи потенциал, татар халкының милли-мәдәни традицияләре аша үстерүне максат итеп куя. Акыл эшчәнлеген яхшырту өчен, логик биремнәр бастырабыз. Укытучыларга журналда урын алган ачык дәресләр дә ярдәмгә килер дип ышанабыз.

**Ахыры 2нче биттә.**

## ● Сайлаулар – 2011

# Сайлауга барасыңмы?

**Динә МӨХТӘСИПОВА,**
хәбәрче

Алда бөтен Россия халкын зур чара – РФ Дәүләт Думасына VI чакырылыш сайлаулар көтә. Беренче мәртәбә Дәүләт Думасы 5 елга сайланачак. Кайсы гына мәгълүмат чарасын карама, бөтен җирдә шул турыда сүз бара. Мәҗбүри тавыш бирергә дигән сүзләр яңгырамаса да, һәркем сайлауларга ашыга. Кем белә бит, бәлки менә шул синең бер тавышың бик мөһим роль уйнар. Безнең укучылар арасында да ил язмышына битараф булмаганнар күптер. Сайлауларда актив катнашырга чакырабыз.

**Ахыры 2нче биттә.**






# Җиңүче «тылсым»чылар

Башы 1нче биттә.

Бик аз вакыт эчендә шактый уңышларга ирештек. Хәтта чит төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез дә кызыксына», – дип фикерләре белән уртаклашты баш мөхәррир Ландыш ханым. Материаллар журналда бастырылып кына калмый, хезмәткәрләр, балалар белән очрашып, мастер-класслар да уздыра. Милли зәвык белән уйлап табылган Түбәтәй һәм Ак калфак персонажлары нәни укучыларның якын дусларына әйләнер. Яңа елдан журнал яңа сәхифәләргә байый.

Бердәнбер татарча проектның җиңүгә ирешүе – безнең өчен зур горурлык. Һәр уңышның нигезендә тырышлык ята һәм һәрвакыт беренче булырга омтылырга кирәк. «Җөмһүриятебез җитәкчеләре безнең алда зур мөмкинлекләр ача. Яшьләр актив булсыннар иде. Тел бетә дип, тик ятарга кирәкми. Тырышырга, бар җирдә дә катнашырга, үзебезне бары тик яхшы яктан гына күрсәтергә кирәк», – диде Ландыш Фазуллина.

Коллегабызны зур җиңүе белән тәбрик итәбез. Калганнар да Сездән үрнәк алсыннар иде дигән теләктә калабыз.

# Сайлауга барасыңмы?

Башы 1нче биттә.

***Айдар Кәлимуллин, КФУның Педагогика һәм психология институты директоры:*** «Сайлау культурасы һәр кешедә булырга тиеш. Һәм без, укытучылар, аны студентларда тәрбиялибез дә. Сайлау хокукын дөрес файдаланырга кирәк. Агитация эшләре алып бару безнең вазифага керми, һәр кешенең үз фикере. Бары тик читтә калмау мөһим».

***Фәнил Гыйләҗев, яшь шагыйрь:*** «Әлегәчә бер дә барганым булмады. Быел барып күреп кайтырга исәп...»

***Равилә Әхмәтова, КФУның Идарә итү һәм территориаль үсеш институты студенты:*** «Сайлау – ул кемдер мәҗбүр иткәнгә генә «галочка» кую түгел. Ул – киләчәк язмышыңны сайлау. Илебез белән әйткән сүзләрен җилгә очыручы партияләр идарә итүен теләмәс идек. Партия ул – халык мәнфәгатьләрен кайгырта торган сәяси оешма. Алар барысы да бертөрле, ләкин һәркайсының үз функцияләре, үз тәкъдимнәре, үз фикерләре бар. Шуңа күрә сайлар алдыннан алар эшчәнлеге белән яхшылап танышырга, моны сайласам, миңа нәрсә бирә, дигән сорау куярга кирәк. 4 декабрьдә узачак сайлауларда халык ялгышмас дип уйлыйм».


***Раил Шәмсетдинов, Казан энергетика техникумы укытучысы, педагогика фәннәре кандидаты:*** «Сайлаулар булган, бар һәм булачак... Халык нәрсә генә уйласа да, алар конституция нигезендә уза. Дөресен генә әйткәндә, хәзерге вакыттагы сайлауларны барыбер дөрес дип уйлыйм... Мин, әлбәттә, сайлауга барам. Һәм хәзерге хөкүмәт өчен тавыш бирәчәкмен... Аларның эшчәнлегеннән бик канәгать, чөнки тотрыклылык бар. Башкалар килсә, әле үз җаен алганчы тагын 5 ел узып китәчәк... »

# КФУда яңа Гыйльми совет

**Рәдифә ШӘФЫЙКОВА,**
ksu.ru сайты хәбәрчесе

КФУның соңгы Гыйльми советы утырышы дүрт вузны берләштерү вакытына – 2011 елның 25 февраленә туры килгән иде. Анда дүрт Гыйльми советтан 165 кеше катнашты. Яңа состав 89 кешедән тора.





Яңа Гыйльми советка сайлаулар 25 ноябрь көнне узды. Конференциядә вузның хезмәткәрләр һәм белем алучылар категорияләреннән 376 делегат катнашты. Көн тәртибенә КФУ Уставына үзгәрешләр кертү; университетның яңа коллектив договоры белән танышу; Гыйльми советка яңа состав сайлау; КФУның бүгенге торышы һәм үсеш перспективалары белән танышу кебек мәсьәләләр куелган иде.

Беренче сорау буенча Михаил Челышев чыгыш ясады. Ул КФУ Уставына 4 блок үзгәреш тәкъдим итте. Яңа «Казан (Идел буе) федераль университеты» исеме барлыкка килү; университетның структур бүленешләре арту; Яр Чаллы һәм Алабуга шәһәрләрендәге филиалларның КФУ институты статусын алуы турында сөйләнде.

КФУның яңа коллектив договоры проекты белән юридик идарә бүлеге җитәкчесе Гөлназ Сибгатуллина таныштырды. Яңа договорда социаль түләүләр күләмен арттыру каралган. Мәсәлән, вуз хезмәткәрләренә, балаларына сәламәтләндерү лагеренә, санаторийларга юлламалар бирү, яңа елга бүләкләр алу шундыйлардан. Лаеклы ялга чыккан алдынгы профессор һәм доцентларга аерым казанышлары өчен махсус премияләр түләнәчәк.

Алга таба Гыйльми советның яңа составына сайлаулар булды. Вазифа буенча Гыйльми советка ректорат әгъзалары керә, калганнар конференциядә сайлана.

Конференция кысаларында ректор Илшат Гафуров институт-факультетлар, кафедралар, студент-аспирантлар, укытучылар саны, күчемсез милек объектлары турында статистик мәгълүматлар китерде, университетның өстенлекле үсеш юнәлешләре турында сөйләде. Уку йортының фән өлкәсендәге халыкара хезмәттәшлекләренә дә басым ясалды, гомумән, вузның хәзерге тормыш картинасы ачылды.

Конференцияахырындасанау комиссиясе сайлау нәтиҗәләре белән таныштырды. Гыйльми совет әгъзалары сайланган дип игълан ителде.



Алия Галимуллина фотолары

● Безнең юбиляр

# Нурлы фәһем иясе

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Филология һәм сәнгать институты татар филологиясе бүлегенең хәзерге татар теле һәм укыту методика кафедрасы профессоры, филология фәннәре докторы Фәһимә Миргали кызы Хисамовага бу көннәрдә 75 яшь тулды.

Күпсанлы студентларның яраткан укытучысы дүрт дистәдән артык ел дәвамында татар теленең фонетикасы һәм морфологиясе буенча лекцияләр укый, гамәли дәресләр алып бара, галимнәр әзерли. «...Үземне бик бәхетле саныйм. Татарлар яшәгән кайсы гына төбәккә барып чыксам да, шәкертләрем белән очрашам. Баштарак аларны энеләрем, сеңелләрем итеп ярата идем, аннары үз балаларым кебек күреп, хәзер инде оныкларым кебек яратам», – ди Фәһимә ханым. Хәзерге көндә ул – тел белеме өлкәсендә әйдәп баручы галимнәрнең берсе. Аның хезмәтләрендә төрле-төрле катлаулы мәсьәләләр күтәрелә. Татар теленең грамматикасы, фигыль сүз төркеме, ягъни күп көч куюны, тирән анализлый белүне сорый торган өлкәләр төп тикшеренү объекты буларак алына.



■ Ф.Хисамова тормыш юлдашы Н.Хисамов белән

Ф.Хисамованың туган телебез морфологиясенә багышланган хезмәте татар тел белеменә генә түгел, гомумтюркологиядә дә зур әһәмияткә ия. Иске татар әдәби теленең кулланылыш өлкәләрен тулырак итеп билгеләүгә багышланган хезмәтләре дә аны халыкара күләмдә таныта. Хөрмәтле юбилярыбызның авылдашы, университеттагы укытучысы, филология фәннәре докторы, профессор Мирфатыйх Зәкиевнең: «Бу югарылыкка аны үз эшенең эчке мантыйгын таба белүе, лингвистик материалларны тулы туплавы, аларга систематик анализ үткәрә алуы һәм нәтиҗәләрне ачык итеп синтезларга сәләтле булуы күтәрде», – дип әйтүе күп нәрсәләр хакында сөйли.



■ Университет галимнәре (сулдан уңга) В.Хаков, Д.Тумашева, Ф.Хисамова, А.Әхмәдуллин студентлар төркеме белән (1988 ел)

Ф.Хисамова үзе әйткәнчә, тагын бер юл күрсәтүче остазы академик Диләрә Тумашеваның: «Галим булу өчен әле нык сәламәтлектә, өеңдә көчле тылың да булырга тиеш», – дигән сүзләре нәкъ Фәһимә ханым һәм «Кыйссаи Йосыф» китабын хәзерге татар теленә шигъри тәрҗемә итеп кенә дә тарихи милли мирасыбызны саклауга зур өлеш керткән академик-галим Нурмөхәммәт Шаһвәли улының дус-тату гаиләләренә туры килә. Өйләнмәгән егет көнләшерлек итеп яшәүнең серләрен тирән аңлаган бу матур пар, берберсенең кадерен белеп, татар дөньясының фән илендә әле дә хезмәттә. Бәйрәмегез мөбарәк булсын, мең яшәгез, хөрмәтле Фәһимә ханым!

**Аталар сүзе – акылның үзе**

# Җәүһәрләрне - сандыкка!

**Лилия БӘДРЕТДИНОВА,**
хәбәрче

Узган атнада татар филологиясе бүлеге студентларының фольклор практикасы буенча йомгаклау конференциясе узды. Күркәм традициягә әверелгән әлеге чара бөтен III курс студентларын җыя. Татар әдәбияты тарихы кафедрасы доценты Луиза Җамалиева конференцияне һәр елны мавыктыргыч һәм эчтәлекле итеп уздырырга тырыша.



Быелгы практикантлар эшләренә бик җитди караганнар, нәтиҗәләр кызыклы. Гадәттәгечә, студентлар фольклор практикасын үзләре яшәгән төбәктә узган. Практика нәтиҗәләре тупланган папкаларның беренче битләрендә авыллар тарихы белән бәйле топонимик риваятьләр, җирле музейлардан алынган мәгълүматлар, фоторәсемнәр тупланган. Барлыгы кырыкка якын авыл турындагы материалларны берләштереп, бик кызыклы презентация дә әзерләгәннәр.

Информантлар, әңгәмә барышында килеп чыккан кызыклы хәлләр турында да бик яратып сөйләделәр. Һәрбер эштә дип әйтерлек аларның сорауларына җавап биргән абый-апаларның фотолары урын алган. Гөлинә Миннебаева хәтта авылдагы бер төркем әбиләрне җыеп, алар өчен бәйрәм ясаган. Үз чиратында, әбиләр дә бик тырышып белгәннәре белән уртаклашканнар.

Иң кызыклы һәм бай материаллар йола иҗатына карый. Кайбыч районының керәшен авылларында үткәрелә торган туй йолаlarының хәзерге вакытка кадәр сакланып калган үзенчәлекләре турында Татьяна Леонтьева сөйләде. Әбисенең милли күлмәкләрен киюе чыгышны тагын да җанландырып җибәрде. Язгы календарь йолаларының берсе – «Май чабу» (Масленица) вакытында башкарыла торган җырны да иптәшләре бик яратып кабул итте.

Хәрби хезмәткә озату белән бәйле йолалар, ышанулар да күп эшләрдә очрый. Бу темага иң кызыклы материалны Раилә Бикчәнтәева туплаган.

Өмәләрдән башка елларда, нигездә, каз өмәсе турында гына материаллар була иде. Быел исә Айгөл Карабаева тула, шәл, печән җыю, җитен эшкәртү һ.б өмәләр турында кызыклы гына мәгълүматлар җиткерде.

Студентларның бәетләр, мөнәҗәтләр белән кызыксынуы шулай ук игътибарга лаек. Җыелган бәетләрнең тематикасы күптөрле. Шулай да иң зур өлешне юл-транспорт фаҗигасе белән бәйле бәетләр алып тора. Быелгы практика вакытында Бөек Ватан сугышы елларында ачлыктан үлгән хатын, бер уч бодай урлаганга төрмәгә утыртылган 15 яшьлек кыз турында инде шактый еллар элек язылган бәетләр табылды. Шул ук вакытта Л.Җамалиева, башка еллардан аермалы буларак, сатирик эчтәлектәге бәетләрнең дә күп булуына басым ясады. «Бәрәнге» һәм «Жевачка»га багышланган бәетләр белән сезне алдагы саннарда таныштырырбыз. Мифологик сөйләкләр, ырым-ышануларга да мисаллар шактый.

Соңгы елларда студентлар фольклоры аеруча популяр. Моның буенча шулай ук эчтәлекле видеоязма әзерләгәннәр. Студент халкының ышанучан, актив, креатив, шул ук вакытта самими күңелле, гади икәнлекләрен күреп була иде.

Тәмле әйбер күп булмый, дигәндәй, конференция сизелмичә генә узып та китте. Материаллар, чыгыш ясарга теләүчеләр күп, вакыт кына аз шул... Афәрин, дуслар! Эш һәм ялны бергә бик матур алып баргансыз. Алдагы елларда да студентлар, үткәнгә битараф калмыйча, милли-мәдәни җәүһәрләребезне зур бер сандыкка туплау эшенә үз өлешләрен кертерләр дип уйлыйм.

**Тәүге адымнар**

# Мөгаллимнәр сере

**Зәһрә ШАКИРОВА,**
татар филологиясе бүлеге студенты

Тиздән педагогик практика җитүен күздә тотып, без – татар филологиясе бүлегенең IV курс студентлары «Уку-укыту системалары белән идарә итү» дисциплинасын алып баручы Светлана Егерева җитәкчелегендә Казан шәһәре Вахитов районының 1нче мәктәбендә булып кайттык.

Максатыбыз – уку-укыту системасында яңа мәгълүмати технологияләр куллану буенча тәҗрибә туплау, талантлы, үз эшенә чын күңелдән бирелгән укытучыларның дәресләрен карау, өйрәнү. Укытучыбызның нәкъ менә әлеге мәктәпкә алып килүе юкка булмаган икән: аннан үзебез өчен бик күп файдалы «багаж» алып кайттык. Биредә ачык дәресләрдә һәм педагогик киңәшмәдә катнашу мөмкинлеге туды. Мин III сыйныфларда татар әдәбияты дәресенә эләктем. Дәреснең оештырылуы һәм укучыларның активлыгы чын-чынлап соклану хисләре уятты.

Рус сыйныфы булуга карамастан, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Айсинә Кәлимуллина балаларда телебезгә кызыксыну тудыра ала, дәресне авырданрак үзләштергән укучыларның җитешсезлекләрен дә «бармак төртеп» күрсәтми. Инаят Хан Һидаят сүзләре белән әйткәндә, «чын укытучы буларак, һәртөрле житешмәгән якларны кисәтүләрне читләп үтеп, укучысының язуы сыйфатларын көн яктысына алып чыга һәм көчсез үсентеләргә дөрес юнәлеш бирә ул». Укучылар бер генә минут та тик утырмыйлар: һәр биремне тиз эләктереп алалар һәм башкарып чыгалар. Бу өлкәдә аларга уйланып һәм кызыклы итеп төзелгән презентация, уеннар, баш ваткычлар ярдәмгә килә. Тагын да төгәлрәк әйткәндә, яңа мәгълүмати технологияләргә таянып укыту дәресне эчтәлекле генә түгел, мавыктыргыч итә, ялыктырмый.

«Балалар мондый дәресләрне бик яраталар, шуңа күрә презентацияләрне мин һәр дәрес өчен ясыйм. Башлангыч сыйныфларда рус балаларына татар телен өйрәтү өчен бигрәк тә уен рәвешендә диалог төзетү уңышлы», – дип фикерләре белән уртаклашты Айсинә Кәлимуллина. Аның балаларны яратуы, белем бирүгә бөтен күңелен салуы күренеп тора.

Педагогик киңәшмә әлеге мәктәптә яңа технологияләр кулланып укытуның, дистанцион белем бирүнең югары дәрәҗәдә булуын күрсәтте. Һәр укытучы үз предметы буенча үз юнәлешен салган, үз программасын төзегән, күргәзмә материаллар эшләгән. Иҗат лабораторияләре дә бар һәм алар яңа технологияләр куллану буенча максатчан эш алып баралар.

Безгә, тиздән мәктәп бусагасыннан укучы буларак түгел, ә укытучы апа-абыйлар булып атлап керәсе студентларга, бу чара киңәш тә, үрнәк тә булды. Укучыларны үз фәнең белән ничек кызыксындырырга, аларның күңеленә юл табарга өйрәтте.



**Хак-нахак**

# Ашасам - исән калырмынмы?

**Айгөл ҖӘЛӘЛОВА,**
юридик факультет студенты

Озак күрешмәгән дустымны очраттым. Студент ашказанының кычкыруын бераз бастырыйк дип, кафега киттек.




Шулай тәмләп кенә ашап утырганда (дустымны да әйтер идем инде, аппетитны бозып утыра!), ул уку йортындагы ашханәдә аштан таракан чыгуын һәм ипи кисәгенең күгәргән булуын әйтте. Ашыйсы килүем сүрелә башлады, әлбәттә. Дустымның шуның хәтле ачуы килгән ки, ул судка мөрәҗәгать итәргә уйлаган. «Гади кешеләрдән көлмәсеннәр шулай, студент халкыннан бигрәк тә. Кечкә эшләп тапкан акчаны тараканлы ашка әрәм итәсе килми бит инде», – ди ачудан кызарып беткән дустым.

Тормышта мондый хәлгә еш юлыгасың, чөнки ашау – яшәү чыганагы. Кеше ашаудан башка тора алмый, бу бик мөһим мәсьәлә. Ач кеше, ризыкның бәясенә дә, сыйфатына да карап тормыйча, тизрәк ашарга керешә. Әлеге биологик процесс һәрберебезгә дә хас, моның белән көрәшү мөмкин түгел. Ачның ачуы яман, диләр. Дустым шул вакыттан бирле кешечә ашый алмый икән, тараканның тәпиләрен күз алдына китерәм дә ачуым кабара гына бара, ди.

Сыйфатсыз продукция белән тәэмин итү, кешеләргә шуны ашату хокук ягыннан катгый тыела. Тик бу теоретик яктан гына шулай. Чөнки бу өлкәдә үзеңнең хаклылыгыңны исбатлау бик авыр, тик мөмкин эш. Административ хокук бозулар кодексы буенча, гаепле булган вазифаи затлар 146.3 һәм 146.4 маддәләр буенча, ягъни товарны конфискацияләү юлы белән җаваплылыкка тартыла. Шулай ук «Халыкның санитар һәм эпидемиологик халәтенең иминлеге» турындагы федераль законнан чыгып, вазифаи затларга 3 айлык керемнәреннән дә кимрәк булмаган күләмдә штраф салынырга мөмкин.

Оешма җитәкчесе санитар нормаларны үтәмичә хокук бозган хезмәткәрләрне дисциплинар җаваплылыкка тартырга тиеш. Закон, Санитар-эпидемиологик хезмәтнең карары физик затны канәгатьләндермәсә, аның 30 календарь көн аралыгында дәүләт санитар табибына мөрәҗәгать итә алуы турында да искәртә. Бу карар да канәгатьләндермәгән очракта, зыян күрүче хөкем йортына шикаять бирә ала.

«Бер санкциядән икенчесенә йөргәндә, бик арырсың инде, шуңа күрә үзең белән ашарга өеңнән алып йөр», – диеп дустымны шаярттым да унышлар теләдем. Аннары соң уйга калдым. Нинди генә ашханәләрдә, кафе-рестораннарда ашамыйбыз бит. Ә пешекченең ничек, нәрсәдән пешергәнен күз белән күреп белмибез, ашаган вакытта бу турыда уйламыйбыз да. Әллә көләргә, әллә еларга?! Әни пешергән ризыкларга бернәрсә дә җитми шул инде! Тәме, чисталыгы, өлгерлеге буенча да... Эх, әни өчпочмакларының исе кытыклаган кебек булып китте борынымны. Житәр, ахрысы, ризык хакында. Җәмәгать, игътибарлы булыгыз! Тыштан матур күренгән ризык әле ашарга яраклы дигән сүз түгел!

**СПИДка каршы көрәш көне**

# Чор чире



**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Бүгенге көндә СПИД эпидемиясенең никадәр дәрәҗәдә глобаль проблема булуын һәр икенче кеше белә. Алдагы гасырларда чума, холера ише афәт кешелекне аяктан екса, бүген исә тагын да көчлерәге – ВИЧ-инфекция дигәне таралды.

1981 елны Америкада авыруларны контрольдә тоту үзәге яңа авыруны терки һәм СПИД (синдром приобретенного иммунодефицита) дип исем бирә. СПИДка каршы көрәш көне беренче тапкыр 1988 елның 1 декабрендә билгеләп үтелә. Көрәш символы булып кызыл тасма исәпләнә. Бер генә акция дә әлеге тасмадан башка уздырылмый.

Ел саен бу көнне эпидемиягә каршы көрәш чаралары турында фикер алышулар бара, ситуацияне җиңеләйтү юллары эзләнә.

ВИЧ – сәламәтлекне какшатучы, икенче төрле әйткәндә, кешене үлемгә илтә торган вирус. Ул бер кешедән икенчесенә кан аркылы яисә җенси мөнәсәбәт вакытында күчәргә мөмкин. Бүген ВИЧ/СПИДны вакытлыча дәваларга мөмкин, әмма тулысынча бетерү чаралары әле уйлап табылмаган. Бу уңайдан кайбер статистик мәгълүматларны китерәсем килә: дөньяда 34 миллион кеше СПИД диагнозы белән яши һәм аларның күпчелеге үзләрендә әлеге гомерлек чир булуын белми дә; СПИД белән авыручыларның 12 миллионы 15-24 яшьлекләр; һәркөнне 7400 кеше ВИЧ инфекциясен йоктыра; яшь кызлар егетләргә караганда ВИЧ инфекциясен өч тапкыр тизрәк эләктерә; 2007 елда СПИД диагнозы белән 2 миллион кешенең гомере өзелгән; әлеге вирусны йөртүчеләрнең 96% алга киткән илләрдә яши.

Уйлап карасаң, СПИД – сәламәтлек белән генә бәйле булган проблема түгел, ә илнең үсешен юкка чыгаручы фактор. Чөнки инфекцияннең яшьләр арасында таралуы эшкә яраклы шәхесләрнең юкка чыгуына китерә. Ә бу исә икътисадка да, җәмгыятькә дә, гаиләгә дә, хәтта мәктәпкә дә – гомумән, бөтен кешелеккә тискәре йогынты ясый. Сак булыйк!

## Илһам канатында



**Булат ИБРАҺИМ** – күпләргә исеме һәм иҗаты таныш яшь шагыйрьләребезнең берсе. Ул 1990 елның 19 октябрендә Лаеш районы Атабай авылында туган. Татар филологиясе бүлегендә IV курста белем ала.

***

*Курка-курка бүген ике телсез,*
*Куллар болгый-болгый дөньясына,*
*Каһәр төшкән, диләр, әллә шунда*
*Тәгәрәгән инде дөньясы да.*
*Калтыранып кына җилне коча күптән*
*Зинданнарда атмый калган таңнар.*
*Ярсып-ярсып канаган күңелне,*
*Белмим, инде хәзер кемнәр аңлар?*
*Кайтаваз да хәзер өзек-өзек,*
*Сызык-сызык булып сибелә.*
*Телсез заман яңа дәүләт төзи,*
*Миңа никтер шулай сизелә.*
*Телсез заман яңа дәүләт төзи,*
*Диварларны ватып-җимереп,*
*Үз яманын ямаулыкка төреп,*
*Манарадан аска төкереп.*
*Телсез заман яңа дәүләт төзи,*
*Артык телләләрен үтереп.*
*Әнә анда минем яшьти ауный,*
*Караңгыдан түеп,исереп.*
*Алар анда яңа дәүләт төзи,*
*Яңа кояш элеп буш күккә.*
*Без үзебез акылдан шашканнар*
*Һәм шашканнар никтер бик күпкә.*
*Нинди дәва язар безгә язлар?*
*Бу ясалма чирдән ни бирер?*
*Ике телсез, куллар болгый-болгый,*
*Үз ишләрен эзләп йөгерер.*
*Йөгерер дә алар сикерерләр*
*Диңгез диеп чиксез упкынга.*
*Телсез дөнья илсез дәүләт төзи –*
*Кәгазь дәүләт яңа буынга.*



***

*Казан кар астында күмелеп ята,*
*Карлар күмгән йортлар арасын.*
Һ.Такташ

*Бөтәрләнеп, бөгәрләнеп бетеп,*
*Казан кар астында күмелеп ята.*
*Әй, абыйлар, тизрәк кыймылдагыз,*
*Тиздән, тиздән инде таң ата.*
*Тракторлар арган юлчы кебек*
*Иренеп кенә торып китәләр.*
*Карга бата-чума кара мәче үтә,*
*«Хәерлегә булсын иртәләр».*
*«Хәерлегә булсын иртәләр»,– ди*
*Кара мәче үзе, куркынып.*
*Тар сукмактан тимер юлга тиеп,*
*Машиналар үтә ыжгырып.*
*Кар астында күмелеп ята бирә*
*Матур-матур, гүзәл бакчалар.*
*Хәзер инде шушы матурлыктан*
*Күзен сирпеп үтми Наташалар,*
*Машалар, Сашалар.*
*Казан кар астында күмелеп ята,*
*Казыйлар да кабат күмелә.*
*Галстуклы тәти абыйларның*
*Кабат бүген башы иелә.*
*«Ә иртәгә бер тамчы кар калмас»!*
*«Ә кем әйтте?»*
*«Мин ишеттем бары кешедән».*
*«Димәк, иртәгәгә кызык булыр,*
*Сүзең булса үзең ишедән».*
*Бөгәрләнеп, бөтәрләнеп бетеп,*
*Юрган астын саклап яткан мәлдә,*
*Акылыннан шашкан тавыш белән*
*Телефоным җырлый бүлмәдә.*
*– Алло, алло,*
*Абый, ач тәрәзең,*
*Ап-ак карның башына җиткәннәр,*
*Әллә нинди язу-мазар сызып,*
*Ап-ак карны алып киткәннәр.*
*– Чынлап әллә?*
*Тукта, куймыйча тор,*
*Бер күз атыйм әле тәрәздән...*
*Ышанмаслык: бер бөртек калмаган,*
*Урлаганнар карны каладан.*
*– Алло, алло, ә кем алып киткән,*
*Урлаганнар әллә, басканнар?*
*– Әйе, абый, урлаганнар карны,*
*Кытайларга урлап сатканнар.*

## Дөнья үзебезнеке

# Косметиканың яшерен көче

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Бер генә көндәшегез дә күз тидермәсен дисәгез – нишләргә? Хөрмәтле хатын-кызлар! Күз кабагының кырыена нечкә генә итеп сөрмә сызып алсагыз, сезгә бер куркыныч та янамас. Алай гына да түгел, күз карашыгыз башкаларны үзенә җәлеп итәр һәм теләкләрегезне җиткерү дә җиңелрәк булыр.



Игътибар иткәнегез бардыр: косметиканың магик көчен аңлаган хатын-кыз бер күрүдән үк үзенә каратырлык итеп бизәнә белә. Гомумән, бүгенге сөйләшүебез косметиканың кайбер кимчелекләрне төзәтү һәм уңай якларны ассызыклап күрсәтү турында гына түгел. Бик борынгы заманнарда, магик ритуаллар башкарылган вакытларда, биткә төрле буяулар сылау булган (кайбер халыкларда хәзер дә бар). Элгәреге аучылар, хәрбиләр, жрецлар һәм шаманнарны искә төшерик әле: аларның йөзендәге һәр сызык, тап аерым бер символик мәгънә белдергән. Дөресрәге, магик мәгънә. Шуңа күрә дә бу көчле коралны шул заманнардагы «беренче леди»лар үзләренеке иткәннәр, әкренләп косметика серләренә төшенә башлаганнар. Ә бу сәнгатьнең ныклап чәчәк атуы Мисырда фараоннар заманына туры килә. Шунысын да әйтергә кирәк: хәзерге көндә без куллана торган косметиканың барлыкка килүе һәм магик макияжның принципларын төзү дә шул җирдәге жрецлар тарафыннан эшләнелгән.

«Косметика» сүзе бизәү сәнгате дип аңлатыла. Б.э.к. 5 мең ел элек беренче Мисыр медицина трактаты төзелә. XIX гасырда аны «Папирус Эберс» дип исемлиләр. Монда косметика кагыйдәләре һәм рецептлары язылган була.

Буяулар, беренче чиратта, усал көчләрдән һәм яшерен дошманнардан саклану чарасы булырга тиеш булган. Күзләр өчен ясалган макияж аерым бер магик үзенчәлеккә ия. Фараоннар һәм Борынгы Мисырда ирләр дә, хатын-кызлар да күз кырыйларына кара сөрмә сызганнар һәм күз кабакларын төрле төскә буяганнар. Болай бизәнүнең, беренче чиратта, аларның югары социаль катламнан икәнлекне күрсәткәнне, икенчедән, кара төстәге сөрмә һәм бизәнгечләр явыз көчләрдән саклану чарасы булуны, өченчедән, мондый күзләрне игътибарсыз калдырып булмаганны белгәннәр. Күзне көрән төсләр белән буяганда, күз карашы алай ук агрессив түгел, йомшаграк була дип санаганнар. Мисыр хатын-кызлары күз кырыйларын зәңгәргә буяуны бик хупламаган. Ни өчен дигәндә, мондый күзләр ир-егетләрне этәрергә мөмкин яисә чибәркәйнең әлегә роман корырга теләге юклыкны аңлаткан.

Иннекнең дә төрле төстәгесен кулланганнар. Алсу төстәге иннек, мәсәлән, хатын-кыз иренен тылсымлы рәвештә үзгәртеп кую көченә ия. Косметичкабыздагы тагын бер магик талисман – ул тырнак буявы. Борынгы Мисырда лаклар булмаган, шулай да гүзәл затлар тырнакларын үстереп, нәфис итеп игәүләп буяганнар. Беренчедән, ачык итеп буялган, очлы тырнаклар усал көчләрне куркыткан. Икенчедән, бармаклар озынрак булып күренгән, ә тырнакның төсе, игътибарны үзенә юнәлтеп, кулның матурлыгын күрсәткән.

Лак сайлаганда да һәр төснең үз магиясе булуын онытмагыз. Белгәнебезчә, кызыл һәм алсу төс – дәрт, агрессия төсе. Алар кайбер очракларда гына яхшы, көндәлеккә бармыйлар. Көн дә кызыл лак куллансагыз, сезнең өчен бу төснең магик көче бетәчәк. Көрәнсу аксыл, көрән төсләр сезнең тыныч, сабыр һәм практик кеше икәнлегегезне күрсәтә, эчке тигезлекне сакларга ярдәм итә. Француз маникюрын яратучыларның исенә төшерик: ак төс – салкын, шул ук вакытта серле дә. Алсу төсле лак – ягымлы, ә менә җемелди торган ялтыравыклы лак белән бергә алар сезне романтик зат итеп күрсәтәчәк. Ялтыравыклы лак начарлык теләүчеләрдән менә дигән саклану чарасы да. Чөнки сезнең һәр тырнагыгызда – йөзләрчә көзге! Аксыл шәмәхә һәм шәмәхә төсле лакларны башкалардан аерылып торырга, үзенчәлекле булырга теләгәндә буягыз. Бу төс үзегездә ышаныч уятырга да ярдәм итәр.

...Мода күпме генә үзгәрмәсен, урталыкны сайлап, табигыйрәк төсләрне яратучылар сөйкемле дә, матур да күренәләр түгелме?

## Халыкара инвалидлар көне

# Алар – иң-иңнәр...

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Инвалидлар – алар шундый ук кешеләр, ләкин иң-иңнәр, дигән гыйбарәне сезнең дә ишеткәнегез бардыр. 1983-1992 еллар Инвалидлар унъеллыгы дип игълан ителгән була. Бу вакыт арасында аларның җәмгыятьтәге урынын яхшырту өчен, бик күп файдалы эшләр башкарыла. 1992 ел ахырында БМОның Генераль Ассамблеясе 3 декабрьне Халыкара инвалидлар көне дип игълан итә.

Инвалидлык - җәза түгел ул, ә кайбер каршылыклар гына, дип яза бер әфәнде аралашу сайтында. Тормыш шартларына яраклашып, гел алга омтылучы, бер кыенлык алдында да югалып калмый торган кешеләргә карап сокланам. Алар безнең арабызда шундый күп бит!!!

Әгерҗе шәһәрендә яшәүче Диана исемле бер кыз баланы беләм мин. Тумыштан авыру кыз башка яшьтәшләреннән бер дә ким түгел. Хәтта җыр-моңга, биюгә осталыгы белән арттырып та җибәрә әле. Кулыннан килмәгән эше юк. Район дәрәҗәсендәге рәсем, кул эшләре конкурсларында беренчелекне беркемгә дә бирми. Республика күләмендә ирешкән уңышлары да шактый.

Диана, кечкенә генә булуына карамастан, күп авырлыклар күрергә өлгергән. Нарасый үз әнисенә кирәк булмый. Башта Чаллы шәһәре балалар йортына җибәрелә, аннары бер гаилә тәрбиягә ала. Яңа әнинең дә гомере озын булмый. Әти кеше кызчыкны киредән район балалар йортына тапшыра. Яхшы күңелле кешеләр дә бар шул арабызда. Диананы бик акыллы гаилә тәрбиягә ала. Беренче көннәрдән үк алар иң якын кешеләргә әвереләләр. Хәзер инде Диана әти-әнисен, абыйларын уңышлары белән сөендерә. Аларга яраткан сеңелләренең ихлас елмаюы, сау-сәламәт булуы да бик мөһим. Сәйләннән ясаган чәчәкләр, картиналар – якыннары өчен иң зур бүләк. Өйнең һәр почмагына диярлек Диана ясаган кул эшләре эленгән. Түшәмнән идәнгә кадәр сузылган сәйләннән тезелгән гөл бөтен кешене таң калдыра. Сөйкемле Дианаsuccessfully ны дуслары да бик ярата, чөнки ул ачык күңелле, аралашучан, һәрчак ярдәм кулы сузарга әзер. Укытучылары да аны үрнәк укучы буларак мактый.

Киләчәккә планнар корып, зур хыяллар белән яши Диана. Әгерҗе шәһәренең 1нче татар гимназиясендә 9 сыйныфта белем алучы кыз һөнәр үзләштереп, тирә-юньгә матурлык өләшергә тели.

Мондый Кешеләрнең бер генә яшәү кагыйдәсе була ала: үзеңне юкка чыгарырга кешеләргә дә, тормыш шартларына да ирек куярга ярамый. Алар чын мәгънәсендә хөрмәткә, игътибарга лаек, чөнки алар иң-иңнәр бит...





Чулпан Нурмөхәммәтова фотолары

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ

Тираж 999

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, Л.Н.Бәдретдинова, З.Ф.Фәсхиева, Б.Х.Ибраһимов, Э.Р.Ибраһимова
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты

Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Сул Болак ур., 44 й., 6 Б каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: (843) 292-22-91, 89053711571.
Электрон почта: tggpu-tat@yandex.ru. Сайт: ksu.ru

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.

Газета бушлай таратыла